# ТАТАРСТАН ВУЗЛАРЫНДА ТАТАР ТЕЛЕ УКЫТУЧЫЛАРЫНЫҢ БЕЛЕМЕН КҮТӘРҮ КУРСЛАРЫ ОЕШТЫРУ ТӘҖРИБӘСЕННӘН

З.Н. Кириллова
Казан федераль университеты, Казан

Илебезнең социаль-икътисади үсешендәге яңа тенденцияләр, Россия мәгариф системасының Болон процессына керүе югары уку йорты укытучыларының һөнәри осталыгын камилләштерү һәм яңа педагогик алымнар формалаштыру мәсьәләләрен барлыкка китерде. Һөнәри яктан компетентлык, мобильлек, яңа укыту-методик бурычларны иҗади якын килеп хәл итү – хәзерге вуз укытучыларына куела торган таләпләр һәм шул ук вакытта социаль заказ да.

Югары уку йорты укытучыларының һөнәри компетентлыгын үстерү кирәклеге түбәндәгеләр белән дә дәлилләнә: вуз тәмамлаучыларның гомуммәдәни һәм махсус әзерлек дәрәҗәсенә куела торган таләпләр арта бара, белем бирү парадигмалары үзгәрә, укытуның массакүләм-репродуктив форма һәм методларыннан индивидуаль-иҗади төргә күчеш бара, студентларның һөнәри яктан компетентлы белгеч булып чыгулары таләп ителә һ.б.

Белем бирү системасындагы үзгәрешләр, әлбәттә, вузларның татар теле укытучыларын да читләтеп үтмәде. Ләкин алар һәрберсе үз уку йорты чикләрендә эшләп, үзара тәҗрибә уртаклашу, уртак проблемаларны бергәләп хәл итү юлларын эзләү мөмкинлеге юк иде. Югары уку йортларында татар теле укытучылары өчен махсус курслар оештыру идеясе күптән яңгыраса да, аны тормышка ашыру эше һаман кичектерелеп килде. Ниһаять, 2012 нче елның 4-16 июнь көннәрендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тәкъдиме белән Филология һәм сәнгать институты базасында вузларда татар теле укытучыларның белемен күтәрү курслары оештырылды. Татарстанның 14 югары уку йортыннан: Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм сәнгать,  Икътисад һәм финанс институтлары, Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институты, Яр Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты, Казан милли

тикшеренү технология университеты (КНИТУ), Казан милли тикшеренү техника университеты (КГТУ-КАИ), “ТИСБИ” идарә университеты, Казан дәүләт энергетика университеты, Казан дәүләт медицина университеты, Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе, Казан дәүләт аграр университеты, Россия дәүләт сәүдә-икътисад университетының Казан филиалы һәм ТР мәгарифне үстерү институтыннан 30 укытучы курсларда белемен күтәрде.

“Югары уку йортларында татар телен өйрәтүгә заманча якын килү” дип аталган әлеге курсларның программасы 4 модульгә нигезләнеп төзелде: “Телгә өйрәтүнең заманча стратегияләре”, “”Вузда татар теленә өйрәтүнең теория һәм технологияләре”, “Югары уку йортында татар телен укытуның һөнәри юнәлеше” һәм “Вузда татар телен өйрәтүдә предметара интеграция”.

Беренче модульдә нигездә теориягә багышланган лекцияләр урын алды. Аерым алганда, татар әдәби телен өйрәнү, саклау һәм үстерү мәсьәләләрен үз эченә алган (академик М.З. Зәкиев), яңа федераль стандартларга күчү шартларында татар телен укытуның торышына күзәтү ясаган (ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф һәм регионара хезмәттәшлек бүлеге мөдире Р.К. Зиннәтуллин), моннан тыш, җирле телләрнең Европа хартиясе (ИНЭКА доценты Җ.Н. Мостафина), телгә өйрәтүнең халыкара стандартлары (доцент Д.Р. Сабирова), югары уку йортында яңа федераль стандартлар (профессор Л.Л. Салехова) һәм телгә өйрәтүдә компетентлык мәсьәләләренә (профессор Р.Ә. Фәхретдинова) багышланган лекцияләр курста укучыларда зур кызыксыну уятты.

Беренче модульдә югары белем системасындагы яңа федераль стандартлар, Россия югары һөнәри белем бирү системасының үсеш тенденцияләре, мәгариф системасының хокукый һәм норматив нигезләре белән таныштыру беренче бурычлар арасында урын алды. Дәресләрдә яңгыраган мәгълүматлардан күренгәнчә, һәр вуз укытучысына инде яхшы ук таныш булган Болон килешүенең төп максаты – Европада югары белем бирүнең бердәм җирлеген булдыру. Бу, үз чиратында, бакалавриат һәм магистратурада белем алу системасын кертүне, укучыларның һәм укытучыларның аралашуын

үстерүне, вузларда белем алу сыйфатын контрольдә тоту системасын булдыруны, институтлар арасында хезмәттәшлекне киңәйтүне күз алдында тота.

Хәзерге вакытта Болон процессы 47 илне берләштерә. Алар арасында Россия, Төркия, Финляндия, Азәрбәйҗан, Грузия, Литва, Эстония кебек илләр бар. 2003 елның сентябрендә Россия Федерациясе дә Болон процессында катнашучы илләрнең Берлинда узган конференциясендә Болон декларациясенә кул куеп, 2010 елга кадәр әлеге процессның төп принципларын тормышка ашырырга вәгъдә бирде [1].

Белгәнебезчә, Россия вузларының күп өлеше Болон процессына кушылды, әмма Россия җирлегенә яраклаштырылган зачет бирәмлекләре системасы тирәсендә сөйләшүләр һаман дәвам итә. Яшьләр фикеренчә, хәзерге заман кешесе белем алу гына түгел, иҗтимагый эшләрдә дә актив катнашырга тиеш, чөнки бу аның фикер йөртүен киңәйтә. Ә иҗтимагый эшчәнлек алып бару, үз чиратында, лекцияләр, семинарларны калдыруга сәбәп була, нәтиҗәдә активистлар зачет-имтиханнарга кертелми яисә сынауларда түбән балл алуга сәбәп була [2].

Мәгариф системасындагы күп сораулар һәм каршылыклар тудырган үзгәрешләр барлык вуз укытучылары өчен дә уртак мәсьәләләрдән санала, ә курслардагы икенче һәм өченче модульләр исә татар теле укытучыларының гамәли эшчәнлегенә турыдан-туры кагылышлы темаларны эченә алды. Мәсәлән, икенче модуль кысаларында татар теленә өйрәтүнең лингводидактик нигезләре, студентларда лингвистик һәм сөйләм компетенцияләре формалаштыру (доцент К.С. Фәтхуллова), татар теле укытуда интенсив методларны куллану (доцентлар С.Х. Айдарова, Л.Х. Шәяхмәтова), информацион-коммуникацион технологияләрдән файдалану (ассистент Б.Э. Хәкимов, доцент А.Р. Абдрафикова) һәм татар теленнән белемнәрне тикшерү алымнарына (доцент Э.Н. Денмөхәммәтова) багышланган дәресләр уздырылды. Татар теленә өйрәтүдә югары уку йортларының һөнәри юнәлешен исәпкә алуга юнәлдерелгән өченче модульдә исә КФУ доцентлары Г.Р. Мөгътәсимова һәм

Р.Р. Сәләхова гуманитар һәм табигать фәннәре белгечлекләрен үзләштерүче студентларга татар теле укыту үзенчәлекләре хакында сөйләделәр, үзләренең эш алымнары белән таныштырдылар.

Дүртенче модуль югары уку йортларында татар телен өйрәтүдә башка фәннәрне дә куллану мәсьәләләренә багышланды. Бу максат белән күренекле әдәбият галимнәре, профессорлар Х.Й. Миңнегулов, Ф.Г. Галимуллин, Татарстан мәдәнияте тарихы белгече, КНИТУ доценты В.М. Мөшәрова файдалы дәресләр үткәрде, шулай ук рус һәм татар мәдәниятләре диалогына багышланган әңгәмәсе белән профессор Р.Ф. Мөхәммәтшина зур кызыксыну уятты.

Курслардагы дәресләрнең күбесен Филология һәм сәнгать институтының тәрҗемәчелек һәм мәдәниятара багланышлар, татар филологиясе, рус филологиясе һәм сәнгать бүлекләре укытучы-галимнәре уздырды, шулай ук ИНЭКА, КНИТУ укытучылары да җәлеп ителде. Курсларда укучыларның дәресләргә зур җаваплылык белән караулары, актив катнашып утырулары нәтиҗәсендә, ике арада эшлекле диалог барлыкка килде.

Курсларда уку дәвамында татар теле укытучылары үзләренең укыту тәҗрибәләре белән дә бик теләп уртаклаштылар, дәресләрдә алган белемнәрен дә файдаланып, чыгарылыш эше яздылар һәм 15 июньдә уздырылган түгәрәк өстәл барышында хезмәтләренең төп нәтиҗәләрен тәкъдим иттеләр.

Филология һәм сәнгать институты директоры Р.Р. Җамалетдинов, Мәгариф һәм фән министрлыгы вәкиле Р.К. Зиннәтуллин һәм курсларда укытучылар белән узган җыелышларда вузларда татар теле укытучылар үзләрен борчыган сораулар белән дә мөрәҗәгать иттеләр. Аларның җыелышларда, түгәрәк өстәл вакытында һәм дәресләрдә ясаган чыгышларыннан күренгәнчә, укытучыларны кайбер югары уку йортларында татар теле дәресләренә бирелгән сәгатьләрнең саны кыскару, нәтиҗәдә укытучыларның ставкалары кимү яки бөтенләй эшсез калу куркынычы янау бик нык борчый. Моннан тыш, кайбер уку йортларында студентларны ике төркемгә бүлеп укыту мөмкинлеге булмау, вузларның татар теле дәреслекләре,

белгечлек юнәлешләрен исәпкә алып төзелгән уку-укыту әсбаплары белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителмәве, булганнарын камилләштереп яңадан чыгару кирәклеге һ.б. күп төрле мәсьәләләр дә игътибардан читтә калмады. Шулай ук укытучылар Татарстан Республикасы вузларының ректорлар советы каршында эшләүче күп мәдәниятле мәгарифне үстерү буенча вузара координация үзәге карамагында югары уку йортларында татар теле укытучыларның методик советын оештыру тәкъдиме белән дә чыктылар. Алда оештырылачак курсларда ачык дәресләр уздыру, педагог сыйфатында рус телен чит тел буларак укытучыларны да чакыру, башка шәһәрләрдән килгән укытучылар өчен мәдәни чаралар оештыру кирәклеге дә ассызыкланды.

Йомгак ясап әйткәндә, вузларда татар теле укытучыларының белемнәрен күтәрү өчен беренче тапкыр оештырылган курслар әлеге эшнең бик кирәкле булуын раслады, бер үк максат белән хезмәт куйган мөгаллимнәрне берләштерү, тәҗрибә уртаклашу, белемнәрен яңарту мөмкинлеге бирде.

Әдәбият

1. Болонский процесс http://ru.wikipedia.org/wiki/%C1%EE%EB%EE%ED%F1%EA%E8%E9_%EF%F0%EE%F6%E5%F1%F1; Болонский процесс: проблемы и перспективы / под ред. М.М. Лебедевой. – Москва: Оргсервис-2000, 2006. – 257 с.; Диалог организационных культур в создании общеевропейского пространства высшего образования: Реализация принципов Болонского процесса в международных образовательных программах с участием России / С.В. Луков (руководитель), Б. Н. Гайдин, В.А. Гневашева, К.Н. Кислицын, Э.К. Погорский ; Моск. гуманит. ун-т, Ин-т фундамент. и приклад. исследований; междунар. акад. наук, отд. гуманит. наук рус. секции. – М.: Изд-во Моск. гуманит. ун-та, 2010. – 260 с. һ.б.

2. ТР парламентында РФ вузларының Болон процессына кушылу үзенчәлекләре турында фикерләштеләр http://tat.gossov.tatarstan.ru/news/show/244